Мәктәп туры

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ
(2025-2026 нчы уку елы)
8 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 120 минут
Максималь балл – 40

I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Борын тартыкларын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [б], [п]
   ә) [к], [г]
   б) [қ], [ғ], [х], [ң]
   в) [м], [н], [ң]

2. Татар алфавитындагы 10 нчы хәрефне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) Е
   ә) Ж
   б) Җ
   в) З

3. Бирелгән фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   Йокы капчыгы
   а) күп әйбер салынган капчык
   ә) буш капчык
   б) йокы яратмаучы
   в) йокы яратучы

4. Бер мәгънәгә генә ия булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) суыткыч
   ә) койрык
   б) тел
   в) кыңгырау

5. Тамырдаш сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) бозгыч, бозлавык
   ә) сөт, сөлге
   б) кис, кистек
   в) бит, битлек

6. Вакыт рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**
   а) җәй

ә) кышын
б) көзге
в) күп

7. Билгеле үткән заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
а) йөгерде
ә) йөгергән
б) йөгерә
в) йөгерер

8. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
Бер рәхмәт мең бәладән коткарыр. (Мәкаль)
а) бер
ә) рәхмәт
б) бәладән
в) коткарыр

II. Теоретик бирем.

Төшеп калган хәрефләрне һәм сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Хәзерге татар әдәби телендә 40 _____ бар. [э] авазы сүз һәм иҗек башында – ___ хәрефе белән, иҗек уртасында һәм ахырында ___ хәрефе белән белдерелә. Мәгънәләре тәңгәл яки бер-берсенә якын торган сүзләр _____ сүзләр дип атала. Тамыр һәм ясагыч кушымча сүзнең _____ тәшкил итә. Татар телендә _____ саны саналмышыннан башка кулланыла.

III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**
глубина – _____ *пояс* – _____
орнамент – _____ *личность* – _____

2. “Минем туган җирем” дигән темага 10 җөмләдән торган инша языгыз. **(14 балл)**